Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXIV-3**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 13 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 24 июлендәге XX-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 26 сентябрендәге 1164 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30, 56, 77 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 24 июлендәге XX-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 5.2 пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль мөлкәтне гавами тәкъдим ярдәмендә, аукционда, конкурста, электрон рәвештә сатканда, муниципаль милектәге акционерлык җәмгыятьләренең акцияләрен махсуслаштырылган аукционда сатканда, сатучы буларак Вәкаләтле орган чыгыш ясый.”;

түбәндәге эчтәлекле икенче абзацны өстәргә:

“Муниципаль мөлкәтне гавами тәкъдим ярдәмендә, аукционда, электрон рәвештә сатканда, муниципаль милектәге акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен махсуслаштырылган аукционда сатканда вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе күрсәтмәсе нигезендә алар белән конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча төзелгән шартнамәләр нигезендә юридик затлар сатучысы функцияләрен гамәлгә ашыруга җәлеп итәргә хокуклы.”;

икенче абзацны өченче абзац дип санарга;

1.2) 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.4. Муниципаль милекне аукционда сату, акционерлык җәмгыятьләре акцияләренең махсуслаштырылган аукционында сату вәкаләтле орган тарафыннан “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда һәм “Аукционда дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне сатуны оештыру турындагы нигезләмәне һәм махсуслаштырылган аукционда акционер җәмгыятьләрнең дәүләт яисә муниципаль милектә булган акцияләрен сатуны оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 12 августындагы 585 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.”;

1.3) түбәндәге эчтәлектәге 5.4(1) пунктын өстәргә:

“5.4(1) Муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сату вәкаләтле орган тарафыннан “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сатуны оештыру һәм уздыру турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 августындагы 860 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.”;

1.4) 7.6 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән юридик затларны җәлеп иткән очракта, мөлкәтне сату-алу шартнамәсен төзү хокукын югалткан җиңүче задаткасы күрсәтелгән юридик затлар тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәсе бюджетына милекне сату-алу шартнамәсен төзү өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып 5 календарь көн эчендә күчерелергә тиеш.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев